РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.02.2021 153-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 1210-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** “Торак өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 1210-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 2.6 пунктындагы таблицаның икенче баганасына түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:
“6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.”;

**1.2.** 3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле бишенче абзац өстәргә: “законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар.”;

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында

һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов